ЯКШӘМБЕ
28 ГЫЙНВАР
1940 ел
№ 22 (5822)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ:
Казан, Матбугат йорты.
ТЕЛЕФОННАР: экономик бүлек 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, культура бүлеге 18—22, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игъланнар бүлеге 2—19.

СОЦИАЛИСТИК АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫНЫҢ ТАГЫН ДА ЧӘЧӘК АТУЫ ӨЧЕН

Бүген авыл хуҗалыгы алдынгыларының республика күләмендәге киңәшмәсе ачыла. Бу киңәшмәнең әһәмияте гаять зур, ул колхозларыбызның тормышында һәм эшендә зур политик вакыйга.

Бу киңәшмәдә 1939 нчы авыл хуҗалыгы елының эшенә йомгак ясалачак һәм 1940 нчы елда авыл хуҗалыгы алдында торган бөек бурычларны үтәү юллары күрсәтеләчәк. Социалистик кырларда иген уңышын тагын да күтәрү, терлекчелекне тагын да үстерү, колхозларыбызны һәр яклап ныгыту, колхозчыларның тормыш-көнкүреш дәрәҗәләрен тагын да яхшырту буенча конкрет чаралар билгеләнәчәк.

Бөек партиябезнең, хөкүмәтебезнең һәм сөекле юлбашчыбыз иптәш Сталинның өзлексез рәвештә кайгыртучанлык күрсәтүләре нәтиҗәсендә, безнең социалистик авыл хуҗалыгыбыз: совхозларыбыз, колхозларыбыз ныгыганнан-ныгый бара һәм колхозчыларыбызның материаль хәле көннән-көн күтәрелә, яхшыра бара, колхоз авылы чәчәк ата. Бөек юлбашчыбыз иптәш Сталин ВКП(б) ның тарихи XVIII нче съездында ясаган докладында илебез алдына гаять зур бурыч куйды:

„Иң якындагы 3—4 ел эчендә гектарыннан уртача 12—13 центнер уңыш алып ел саен 8 миллиард пот ашлык җитештерүгә ирешү өчен, техник культуралар җитештерүне уртача 30—35 процентка арттыру өчен, сарыклар һәм дуңгызлар санын ике өлеш, мөгезле эре терлекләр санын 40 процент чамасына, атлар санын 35 процент чамасына арттыру өчен игенчелегебезнең һәм терлекчелегебезнең күтәрелүен тагын да җәелдерергә“.

Бу катлаулы һәм зур бурычны үтәү өчен бездә бөтен шартлар һәм мөмкинлекләр бар. „Бездә авыл хуҗалыгыбызны, игенчелегебезне культуралы итеп, фән кушканча алып бару өчен һәм аны стихия бәйлелегеннән коткару өчен бөтен нигезләр бар, чөнки бездә моның өчен кирәк булган барлык чаралар диярлек: иң яхшы авыл хуҗалыгы машиналары, вакланган түгел, бәлки эре җир участкылары, җәмагатьләштерелгән хуҗалык һәм бу яктан гаять зур тәҗрибә бар“ (Андреев).

Моның чыннан да шулай икәнлеген без илебезнең меңнәрчә алдынгы колхозлары һәм совхозлары тәҗрибәсендә, республикабызның авыл хуҗалыгы алдынгыларының бай тәҗрибәсендә бик ачык күрәбез.

Югары иген уңышы өчен көрәшне оештыру, агрономия чараларын яхшы итеп үткәрү нәтиҗәсендә, климат шартлары беркадәр начар булуга да карамастан, республикабызның күп кенә колхозлары һәм бригадалары 1939 нчы елда югары иген уңышы алуга ирештеләр. Мисальгә Биектау районы, Буденный исемендәге колхозны, Чаллы районының Чкалов исемендәге колхозын алырга мөмкин. Бу колхозларның беренчесе бөртекле культураларның һәрбер гектарыннан уртача 13,5 центнер, ә икенчесе 15,5 центнер уңыш алуга иреште. Мөслим районы, „Ялкын“ колхозының иптәш Шәймөхәметов җитәкчелек итә торган бригадасы 67 гектар мәйданындагы арышның һәр гектарыннан 22 центнер, Азнакай районы, „Кызыл Байрак“ колхозының бригадиры иптәш Сафа Гарипов 30 гектар мәйданындагы бодайның һәр гектарыннан 16 центнер уңыш алдылар. Мондый фактларны республикабызның күп кенә районнарыннан, колхозларыннан китерергә мөмкин.

Терлекчелек, бакчачылык, яшелчәчелек һәм авыл хуҗалыгының башка тармаклары буенча да гүзәл эш үрнәкләре күрсәткән байтак колхозларны, бригадаларны, звеноларны, алдынгы работникларны күрсәтергә була. Аларның иң яхшылары 1939 нчы елда Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә катнаштылар һәм алар республикабызның барлык хезмәт ияләренә билгеле.

Бүген ачылачак киңәшмәдә катнашучылар—алар барсы да республикабызның авыл хуҗалыгының теге яки бу тармагында алдынгылыкны яулап алган работниклар, социалистик авыл хуҗалыгын тагын да алга җибәрү, үстерү буенча бай тәҗрибәгә ия булган кешеләр.

Бөек Ватаныбызның барлык колхозларында, совхозларында һәм МТС ларында партиябезнең XVIII нче съезды тарафыннан авыл хуҗалыгы өлкәсендә куелган зур бурычларны үтәү өчен көчле көрәш бара. Югары иген уңышы алу өчен, терлекчелекне тагын да үстерү өчен җәелдерелгән социалистик ярыш көннән-көн киң колач ала бара. Сталинград өлкәсенең алдынгы бригадирларының инициативасы буенча башланган йөзпотчылар хәрәкәте бөтен Союз күләмендәге хәрәкәт булып әверелә.

Социалистик игенчелеккә зур яңалыклар кертүчеләрнең—ефремовчыларның бөек тәҗрибәләре нигезендә илебезнең күп кенә районнарында ефремовчы звенолар оештыру эше киң колач ала бара.

Йөзпотчылар хәрәкәтенә республикабызда беренчеләрнең берсе булып кушылган Калинин районы алдынгыларының мөраҗәгате нигезендә безнең барлык районнарыбызда, колхозларыбызда 1940 нчы елда югары иген уңышы алу буенча социалистик ярыш торган саен киң җәелә бара.

Бүген ачыла торган киңәшмәдә катнашучылар авыл хуҗалыгын тагын да ныгыту, аны алга җибәрү өлкәсендә бездә нинди зур мөмкинлекләр барлыкны, ул мөмкинлекләрдән файдалана белгәндә һәм бу эшкә колхозчылар массасын большевикларча туплаганда нинди зур нәтиҗәләргә ирешергә мөмкин икәнлекне үзләренең бай һәм кыйммәтле эш үрнәкләрендә тулы итеп күрсәтерләр. Һәм, шулай итеп, 1940 нчы елда авыл хуҗалыгының барлык тармакларында яңадан-яңа зур уңышларга ирешү юлларын билгеләрләр. Республика күләмендәге бу киңәшмә авыл хуҗалыгы алдынгыларының тәҗрибә мәктәбе булыр.

Партия, совет оешмаларының төп бурычларыннан берсе: алдынгылар хәрәкәтен тагын да киңрәк җәелдерүдән һәм аларның тәҗрибәләрен, казанышларын кулануны барлык колхозларда, совхозларда һәм МТС ларда киң оештырудан гыйбарәт.

ВКП(б) райкомнарының һәм хезмәт ияләре депутатлары район советларының башкарма комитетлары күрсәтүе буенча тракторларга һәм авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясауда яхшы күрсәткечләр биргән алдынгылар һәм стахановчылар Республика Почет Тактасына кертеләләр:

15. Аксубай районы, Аксубай МТС ының үз бригадаларында 1939 нчы елның 24 нче декабренә тракторларга һәм авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясауны тулысынча тәгәлләгән трактор бригадасы бригадирлары **Е. Леонтьев** һәм **А. Мардеев** иптәшләр.

16. Аксубай районы, Иске Тимошкино МТС ының үз бригадасында 1940 нчы елның 10 нчы гыйнварына тракторларга һәм авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясауны тулысынча тәгәлләгән трактор бригадасы бригадиры иптәш **И. Тимонов.**

17. Тымытык районы, Чалпы МТС ының 1939 нчы елның 24 нче декабренә үз тракторларына һәм тагылма инвентарьларга ремонт ясауны тәгәлләгән тракторчылары **Р. Хәсәнев** һәм **И. Ваһапов** иптәшләр.

Авыл хуҗалыгы алдынгыларының республика киңәшмәсе делегатларыннан бер төркем. Сулдан утыралар: З. Кашапов, А. Булатов, Г. Таҗеттинов, Х. Солтанова; артта—(сулдан) С. Сибгатуллин, Г. Тимергалиев, З. Ханнанов, К. Абдуллин һәм Т. Бакеев иптәшләр.

М. Солтанов фотосы.

СССР Верховный Советы Президиумы УКАЗЫ

Кызыл Армиянең начальниклар составына Советлар Союзы Герое дигән исемне бирү турында

Фин ак гвардиячелегенә каршы көрәш фронтында командованиенең хәрби заданиеләрен үрнәк рәвештә үтәүләре һәм бу эштә батырлык һәм геройлык күрсәткәннәре өчен, түбәндәгеләргә, **Ленин ордены** һәм **„Алтын йолдыз“** медале тапшыру белән, **Советлар Союзы Герое** дигән исемне бирергә:

1. Политрук Кесарь Федорович **Андреев.**
2. Кече командир Александр Макарович **Васильев.**
3. Кече политрук Михаил Григорьевич **Манакин.**
4. Лейтенант Петр Тихонович **Михалицын.**

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе М. КАЛИНИН.
СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре А. ГОРКИН.

Москва, Кремль. 26 гыйнвар, 1940 ел.

СССР Верховный Советы Президиумы УКАЗЫ

81 нче Стрелковый-Тау полкын „Кызыл байрак“ ордены белән бүләкләү турында

Фин ак гвардиячелегенә каршы көрәш фронтында командованиенең хәрби заданиеләрен үрнәк рәвештә үтәгәнлеге өчен һәм бу эштә каһәрманлык һәм батырлык күрсәткәнлеге өчен, 81 нче Стрелковый-Тау полкын „Кызыл байрак“ ордены белән бүләкләргә.

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе М. КАЛИНИН.
СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре А. ГОРКИН.

Москва, Кремль. 26 гыйнвар, 1940 ел.

СССР Верховный Советы Президиумы УКАЗЫ

Кызыл армеец Никита Иванович Русинга Советлар Союзы Герое дигән исемне бирү турында

Фин ак гвардиячелегенә каршы көрәш фронтында командованиенең хәрби заданиеләрен үрнәк рәвештә үтәгәнлеге өчен һәм бу эштә батырлык һәм геройлык күрсәткәнлеге өчен

кызыл армеец Никита Иванович **Русинга,**

Ленин Ордены һәм **„Алтын йолдыз“** медале тапшыру белән, **Советлар Союзы герое** дигән исемне бирергә.

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе М. КАЛИНИН.
СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре А. ГОРКИН.

Москва, Кремль. 26 гыйнвар, 1940 ел.

КЫЗЫЛ АРМИЯНЕҢ НАЧАЛЬНИКЛАР ҺӘМ РЯДОВОЙ СОСТАВЫН СССР НЫҢ ОРДЕННАРЫ ҺӘМ МЕДАЛЬЛӘРЕ БЕЛӘН БҮЛӘКЛӘҮ

Фин ак гвардиячелегенә каршы көрәш фронтында командованиенең хәрби заданиеләрен үрнәк рәвештә үтәгәнлекләре өчен һәм бу эштә каһәрманлык һәм батырлык күрсәткәнлекләре өчен, ССР Союзы Верховный Советы Президиумының указлары белән, Кызыл Армиянең начальниклар һәм рядовой составыннан 891 кеше бүләкләнде.

Ленин ордены белән түбәндәгеләр бүләкләнде:

Өлкән лейтенантлар—В. Т. Апостолов, М. И. Арделян, Н. С. Коровин, Фәйзуллахан Камалетдинов, В. А. Бурлов, кече лейтенантлар—В. Я. Волик, М. П. Богатырев, С. И. Сологуб, Я. Н. Погосян, капитаннар—В. П. Гущин, А. М. Кушнир, А. Ф. Родин, А. Я. Шишенков, И. П. Прохоров, А. С. Егоров, Ф. М. Забело, полковник И. Д. Дряхлов, кызыл армеецләр — Ф. А. Гомзяков, В. Т. Медведев, М. М. Иванов, П. Ф. Ципляк, кече командирлар—И. К. Шевченко, И. В. Наумов, И. В. Скочнягин, Н. Н. Баскаков, С. П. Пушкин, политруклар — П. М. Полежак, Д. Д. Пустовит, А. А. Ельцов, комбриг П. Г. Понеделин, кече политрук И. А. Ершов, майорлар—С. Я. Симоненко, Г. А. Вещезерский, Д. П. Турбина, өлкән военфельдшер И. И. Громов.

„Кызыл байрак“ ордены белән 375 кеше бүләкләнде. Алар арасында түбәндәгеләр бар: кызыл армеецләр—П. В. Андреев, И. И. Абаз, А. С. Баранов, С. А. Белов, Д. М. Борисов, А. М. Волков, В. П. Гай, А. И. Ефимов, А. И. Ковалев, В. И. Костин, П. В. Лосев, З. Е. Неделько, И. М. Марков, Д. В. Пайхало, А. М. Рыжов, В. А. Тищенко, М. Я. Яковлев, кече командирлар—Н. П. Абрамов, Г. М. Басевич, А. В. Дмитриев — Лунев, Р. А. Коротич, И. Т. Маслов, П. П. Слепнев, Н. М. Фомин, И. Н. Ященко, 3 нче ранг военврачлар—Е. П. Андреева, П. И. Новик, икенче ранг хәрби юрист А. Н. Петров, лейтенантлар—М. А. Алексеев, И. А. Волуев, Н. В. Волгин, С. Д. Сескутов, комбриг Г. Ф. Кондрашев, майорлар—З. Т. Бабаскин, И. Н. Ковашук, военфельдшер Т. В. Битовт, капитаннар—П. И. Кравцов, М. А. Мочалов, батальонный комиссар А. Ф. Павлов һ. б.

„Кызыл йолдыз“ ордены белән 131 кеше бүләкләнде. Алар арасында түбәндәгеләр бар: кызыл армеецлар—М. А. Благушин, И. Ф. Голубь, Д. А. Емелин, И. В. Иванов, В. Ф. Новиков, Ю. М. Куркин, И. М. Русиновский, В. Ф. Соболев, кече командирлар—М. И. Бобылев, С. Г. Василенко, С. Л. Корман, В. П. Корочкин, А. Ф. Яриков, Д. Ф. Ловчиков, А. И. Мельников, лейтенантлар—П. В. Васильев, Д. А. Костюк, комбриг П. С. Пшенников, политрук Г. Р. Шарендо, батальонный комиссарлар — Ф. П. Александров, М. В. Макаров, Ф. Ф. Морозов, 3 нче ранг военврач М. М. Павлова, 3 нче ранг военинженир В. В. Носов һ. б.

„Батырлык өчен“ медале белән 256 кеше, „Сугышчан хезмәтләр күрсәткән өчен“ медале белән 94 кеше бүләкләнделәр.

АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ КҮРГӘЗМӘСЕНӘ КАНДИДАТ БУЛГАН ГАЗЕТАЛАР

СТАЛИНГРАД, 26 гыйнвар. (ТАСС). Һәр гектардан 100 пот иген уңышы алу өчен Бөтенсоюз хәрәкәтен үстерүдә Сталинград өлкәсенең матбугаты оештыручы зур рольне уйнады. ВКП(б) ның Сталинград Өлкә Комитеты, 1940 нчы елда Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә, матбугат павильонында катнашу өчен шушы көннәрдә беренче кандидатларны раслады.

Өлкәнең иң яхшы район газеталарыннан 6 газета, шулай ук ВЛКСМ Өлкә Комитеты органы „Молодой Ленинец“ газетасы, өлкәнең „Сталинградская Правда“ газетасының авыл хуҗалыгы бүлеге, Сталинград трактор заводы газетасы „Даешь трактор“ һәм ТАСС ның өлкә бүлеге кандидатлар итеп күрсәтелделәр.

Алты район газетасының өчесе узган ел Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә катнаштылар. Новоаннен районының „Голос коммунара“ газетасы редакциясе беренче дәрәҗәдәге диплом һәм җиңел автомашина алган иде.

1940 нчы ел, 28 нче гыйнварда кич сәгать 6 да Менжинский исемендәге клубта (Карл Маркс урамы) социалистик авыл хуҗалыгы алдынгыларының республика күләмендәге киңәшмәсе ачыла.

Көн тәртибендә:

1939 нчы авыл хуҗалыгы елының йомгаклары һәм 1940 нчы елгы бурычлар. (Докладчы ВКП(б) Өлкә Комитеты секретаре иптәш Матвеев).

Киңәшмәгә килүче делегатларны Казан вокзалында беренче номерлы залда Татнаркомзем дежурные каршылый.

Делегатларны регистрацияләү Татнаркомзем бинасында 16 нчы бүлмәдә үткәрелә. Телефоннар 8—15 һәм 32—20.

ОЕШТЫРУ КОМИССИЯСЕ.

Ленинград Хәрби Округы Штабының оператив сводкасы

26 нчы гыйнварда фронтта әһәмиятле бер нәрсә дә булмады.

Казан Медицина институтына

ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитеты Казан Медицина институтының галимнәр, фәнни работниклар, укытучылар һәм студентлар коллективын институтның данлыклы 125 еллыгы көнендә кайнар рәвештә котлый.

Институт зур юл үтте. Электә Казан Дәүләт Университетының факультетыннан, совет власте шартларында институт илебезнең эре ВУЗларыннан берсе булып үсте, совет медицина кадрларының, коммунизм эше өчен актив көрәшчеләрнең чын учагы булып әверелде. Медицина институты коллективы Татарстанда сәламәтлек саклау эшен алга җибәрү өчен, Татарстан республикасы өчен генә түгел, бәлки бөтен социалистик Ватаныбыз өчен дә медицина работниклары хәзерләүдә күп эш башкарды.

ВКП(б) Өлкә Комитеты тулы ышаныч белдерә ки, медицина институтының коллективы, югары белемле медицина кадрларын тәрбияләп, аларны Маркс—Энгельс—Ленин—Сталинның җиңүчән таглиматы белән коралландырып, киләчәктә дә алдынгы совет фәненең байрагын югары тотар.

ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитеты.

КАЗАН ДӘҮЛӘТ МЕДИЦИНА ИНСТИТУТЫНЫҢ ПРОФЕССОРЛАР, УКЫТУЧЫЛАР, СТУДЕНТЛАР ҺӘМ ХЕЗМӘТКӘРЛӘР КОЛЛЕКТИВЫНА

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Казан Дәүләт Медицина институтының профессорлар, укытучылар, студентлар һәм хезмәткәрләр коллективын 125 еллык юбилей белән чын күңелдән котлый.

Казан Дәүләт Медицина институты, Советлар Союзының иң карт медицина институтларының берсе буларак, үзенең яшәүе чорында, бигрәк тә Совет власте елларында, йөзләрчә һәм меңнәрчә гүзәл белгечләр, Совет халкының сәламәтлеген саклау буенча үз-үзләрен аямыйча эшләүче Совет медицинасы галимнәре тәрбияләп үстерде.

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы, Казан Медицина институтының сәламәтлек саклау буенча киләчәктә дә югары квалификацияле кадрлар тәрбияләячәгенә, медицина фәнендә яңа казанышлар яулап алуда армыйталмый эшләячәгенә ышана.

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы.

КАЗАН МЕДИЦИНА ИНСТИТУТЫ КОЛЛЕКТИВЫНА

Бөтенсоюз Коммунистлар (большевиклар) Партиясенең Казан Шәһәр Комитеты Казан Медицина институтының фәнни работниклары, хезмәткәрләре һәм студентлары коллективын институтның данлыклы 125 еллыгы көнендә кайнар рәвештә котлый.

Казан Медицина институты үзенең 125 ел яшәү чорында фәнгә бай хәзинә калдырган Лесгафт, Миславский, Арнштейн, Адамюк, Даркшевич, Бехтерев кебек күренекле галимнәрнең бөтен бер семьясен тәрбияләде, бөек Ватаныбызның йөз меңнәрчә яшь галимнәре— Сперанский, Лаврентьев, Осипов, Вишневский һәм күп кенә башкалар аларның хезмәтләрендә тәрбияләнәләр — алар совет фәненең мактанычы булып торалар һәм СССРда гына түгел, бәлки чит илләрдә дә дан тоталар.

Казан Медицина институты, Советлар Союзының зур фәнни учреждениесе буларак, бөек Ватаныбыз өчен бик яхшы медицина кадрларын уңышлы рәвештә хәзерли.

ВКП(б) ның Казан Шәһәр Комитеты, Казан Медицина институты работниклары коллективының иң алдынгы фәне, Маркс—Энгельс—Ленин—Сталин таглиматын нык үзләштереп, киләчәктә дә югары квалификацияле кадрлар хәзерләү өчен, социалистик фәннең һәм культураның чәчәк атуы өчен, ВКП(б) ның XVIII нче съезды тарафыннан һәм бөек юлбашчыбыз иптәш Сталин тарафыннан совет фәне алдына куелган тарихи бурычларны тормышка ашыру өчен көрәшәчәгенә нык ышана.

ВКП(б) ның Казан Шәһәр Комитеты.

Авыл хуҗалыгы алдынгыларының республика күләмендәге киңәшмәсенә карата

СОЦИАЛИСТИК АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫНДА ЯҢА УҢЫШЛАР ӨЧЕН

ЕФРЕМОВЧЫЛАРЧА ЭШЛӘРБЕЗ

Безнең колхоз төзелүгә тугыз ел тулды. Бу еллар колхозны большевистик, колхозчыларны таза тормышлы итү өчен большевикларча көрәш билгесе астында үтте.

Үткән елны һава шартлары беркадәр начар булуга карамастан, бөртекле культуралар буенча без һәр гектардан уртача 14,11 центнер уңыш алуга ирештек. Бәрәңгедән һәм яшелчәдән дә мул уңыш алдык.

2 нче бригадада уңыш тагын да югары булды. Биредә солының һәр гектарыннан 19 центнер, бодайның һәр гектарыннан 18 центнер уңыш чыкты. Колхозчыларның һәр хезмәт көненә 5 килограммнан артык бөртекле ашлык, 7 килограмм бәрәңге, 1,5 килограмм яшелчә һәм 1 сум 60 тиен акча бүлдек. Колхозчы Василий Рязанов семьясе үзенең хезмәт көннәренә 311 пот ашлык, 412 пот бәрәңге, 1.500 сумнан артык акча алды. Николай иптәш Алексеев семьясе 344 пот ашлык, 464 пот бәрәңге, 1.700 сум акча алды.

Бу уңышларга без ничек ирештек соң?

Хезмәтне дөрес оештыру, агротехника чараларын җиренә җиткереп үткәрү, кыр эшләрен югары сыйфатлы итеп иң кыска срокларда башкару—югары уңыш алуны тәэмин иткән төп шартлар әнә шулар.

1939 нчы елның иген уңышы өчен көрәшне без көздән үк башладык. Сабан ашлык чәчеләчәк җирләрне 5 нче сентябрьгә кадәр тунга сөреп калдырдык. Колхозда булган җирле ашламалардан һәм минераль ашламалардан тулысынча файдаландык. 250 гектар мәйданда кар тоттык.

Язгы чәчүне срогында төгәлләдек. Җентекләп хәзерләнгән туфракка югары сыйфатлы, сортлы орлыклар гына чәчтек.

Игеннәрне иң кыска срокларда урып-җыю—югары уңыш өчен көрәштә иң әһәмиятле шартларның берсе. Шунлыктан, без арышны 4 көндә, сабан ашлыгын 7 көндә урып-җыйдык. Кыр эшләре вактында колхозчылар аеруча яхшы эшләделәр. Хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүдә хатын-кызлар зур активлык күрсәттеләр. Алар көлтә бәйләү нормасын югары сыйфатлы итеп 150—175 процент үтәделәр.

Стахановчылардан Александр Рязанов, Михаил Комиссаров, Евдокия Рязанова, Татьяна Феофанова, Николай Алексеев, Анна Укулова иптәшләр хезмәт җитештерүчәнлегенең югары үрнәкләрен бирделәр.

Ефремовчыларның югары иген уңышы алу өчен көрәш тәҗрибәләрен үзләштерү нигезендә, быел тагын да яхшырак эшләү өчен көрәшәбез.

Быел яз бөртекле культуралар чәчеләчәк җирләрне барсын да көздән тунга сөреп калдырдык. 7 тонна минераль ашлама хәзерләдек. Җирле ашламалар җыю эше кызу темп белән бара. Быел да сортлы орлыклар гына чәчәбез. Орлыклар триер аркылы үткәрелде, тикшергәннән соң аларның сыйфаты отлично дип табылды.

Тәҗрибә участкыларында быел шахмат тәртибендә 10 гектар бодай, 5 гектар солы чәчәчәкбез. Үткән язда 3 гектарга чәчелгән солыны тишелеп чыканга кадәр җиңел тырма белән тырмалаган идек. Бу чара солының һәр гектарыннан, башка участкыларга караганда, 3 әр центнер артык уңыш биргәнлеген күрсәтте. Быел бу тәҗрибәне киң күләмдә кулланачакбыз. Тунга сөрелгән җирләрне калаксыз сабаннар белән яз көне 8—10 сантиметр тирәнлегендә сөреп тырмалау, уҗым чәчүлекләрен тирес сыекчасы, аммоний сульфаты һәм тавык тизәге сыекчасы белән тукландыру кебек чараларны быел тагын да киңрәк кулланачакбыз.

Кырчылык бригадаларында даими звенолар, 2 нче бригадада ефремовчылар звеносы оештырдык.

Ефремовчылар звеносы алдында бодай һәм солы уңышын һәр гектардан уртача 30 центнер, бәрәңге уңышын 150 центнер алу бурычы куелды.

Хәзер колхозда ефремовчылар мәктәбе ачылып, 30 кеше укый башлады. Казан Селекция Станциясе работнигы иптәш Попов кар тоту турындагы темага лекция укыды. Агротехника темалары буенча лакцияләрне үткәрүгә район җир бүлегенең өлкән агрономы иптәш Николаев җитәкчелек итә.

Без бөртекле культураларның һәр гектарыннан уртача 18 центнер, тәҗрибә участкыларында 30 ар центнер уңыш алу өчен көрәшәбез. Бу йөкләмәбезне тулысынча үтәячәгебезгә без нык ышанабыз.

Е. Н. Новиков.

Биектау районының Буденный исмендәге колхоз председателе.



Буденный исмендәге колхозның (Биектау районы) алдынгы стахановчысы Евдокия Ивановна Рязанова.

И. Галиев фотосы.

Этнә районы Киров исмендәге колхоз Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә беренче дәрәҗә диплом алды. Хәзер колхоз югары уңыш алу һәм 1940 нчы елгы авыл хуҗалыгы күргәзмәсендә катнашу өчен көрәшә. РӘСЕМДӘ: бригадир Д. Хәлиуллин агро-техника түгәрәгендә занятие үткәрә.

В. Лаврентьев фотосы.

ТЕРЛЕКЧЕЛЕКТӘН 56 МЕҢ СУМ ДОХОД

Безнең сарык асраучылык фермасы 1931 нче елда 300 баш гади сарыклардан оештырылган иде. Беренче елларда ук без сарыкларның нәселен яхшырту чарасын күрдек. 1934 нче елда 3 баш прикос нәселле тәкәләр сатып алып, ясалма орлыкландыру тәҗрибәләре алып бара башладык. Бу тәҗрибә бик уңышлы чыкты. Хәзер безнен фермабызда 810 баш метис һәм чиста нәселле сарыклар һәм тәкәләр бар. Аларның 20 проценты дәүләт нәсел кнәгәсенә язылган.

Сарык асрау хәзер безнең колхозда төп тармак булып тора. Ферманың доходы ел саен үсә. Мәсәлән, 1937 нче елда ферма колхозга 18 мең сум доход биргән булса, 1939 нчы елда 56 мең сум доход бирде. Бу, колхоздагы бөтен доходның яртысыннан артыгырагы дигән сүз.

Сарыкларның продуктлыгы да ел саен арта бара. 1937 нче елда бер олы сарыктан алынган уртача йон 3,75 килограмм булса, 1939 нчы елда уртача 4 килограмм 50 грамм йон алынды. Һәрбер 100 баш сарыктан 1938 нче елда 144 баш бәрән, 1939 нчы елда 125 баш бәрән үстерелде.

Терлекләрне үрчетү буенча дәүләт планын һәр елны тулысынча һәм арттырып үтибез. Бу күрсәткечләр белән безнең фермабыз 1939 нчы елда Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә катнашты һәм почет кнәгәсенә теркәлде.

1940 нчы елда да Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә катнашу өчен безнең ферма кандидат булып тора. 1940 нчы елда һәр 100 баш сарыктан кимендә 125 баш бәрән үстерү һәм һәрбер прикос сарыктан 4,5 килограмм, һәрбер метистан 3 килограмм йон алу турында йөкләмәләр алдык.

Фермадагы барлык кешеләр арасында социалистик ярыш договорлары төзелде һәм „Байкал“ колхозы фермасын ярышка чакырдык. Бу йөкләмәләрне үтәү өчен безнең мөмкинлекләребез зур. Барлык терлекләр чиста, җылы, якты урыннарда торалар. 600 центнер көчле азык, 370 центнер тамыр азыгы, 170 центнер силос, 1.410 центнер печән, 3.360 центнер салам азыкларыбыз бар.

Мин шушы фермада 7 ел чабан булып эшләдем. Хәзер бригадир булып эшлим. Минем эшем бик кызыклы һәм күңелле эш. Мин уңышларым белән райондагы авыл хуҗалыгы күргәзмәсенә катнаштым. Терлекчелек алдынгыларының өлкә киңәшмәсенә бардым һәм берничә тапкыр кыйммәтле бүләкләр белән бүләкләндем.

1939 нчы елда колхозда иң күп хезмәт көне безнең фермада эшләүчеләргә туры килә. Мәсәлән, артелдә бер колхозчы уртача 200 хезмәт көне эшләгән булса, фермадагылар 400—500 хезмәт көне эшләделәр. Ә мин үзем 615 хезмәт көне эшләдем.

Безнең фермада бик яхшы кадрлар үсеп чыктылар. Уннарча колхозчылар ясалма орлыкландыру техникасын, зоотехника кагыйдәләрен үзләштерделәр. Чабаннардан Якупов, Сабиров, Фәйзерахманов һәм Шәмсеттинов иптәшләр яхшы күрсәткечләр бирәләр. Хәзер фермадагы барлык эшләүчеләр зоотехника укуларына тартылдылар. Укулар системалы рәвештә алып барыла.

Партия оешмасы коммунист иптәш Салаховны фермага агитатор итеп беркетте. Иптәш Салахов халыкара хәл һәм башка мәсьәләләр турында көн саен беседалар үткәрә. Шулай итеп, без үзебезнең белемебезне күтәрү өстендә дә тырышып эшлибез.

Низам Әхмәтҗанов.

Теләче районы, „Марс № 2“ колхозының сарык асраучылык фермасы бригадиры.

ГЕКТАРДАН 20 ЦЕНТНЕР УҢЫШ ӨЧЕН

Мамадыш районының „Хәсанша“ колхозы 1939 нчы елны гектарыннан 13 центнер 59 килограмм уңыш алды. Аерым культуралар буенча исәпләгәндә түбәндәгечә: бодай гектарыннан 10 центнер 20 килограмм, арыш 17 центнер 35 килограмм, солы 13 центнер 15 килограмм, арпа 11 центнер 15 килограмм, борчак 11 центнер 6 килограмм.

Бу уңышка без агротехниканы төгәл тормышка ашыру, барлык колхозчыларны югары уңыш өчен көрәшкә туплау, хезмәтне дөрес оештыру нәтиҗәсендә ирештек. Колхозчылар ачык беләләр: уңышны күтәрү—аларның үз кулларында.

Җир тәрбияне ярата. Кырчылыктан югары доход алу өчен җирне агрономия фәне кушканча тәрбияләргә, ашларга кирәк. Без бу эшкә аеруча зур игтибар бирәбез. Бу уңай белән бер мисальгә тукталып үтик. Безнең колхозда орлыклык участкы бар. Бу участкының һәр гектарыннан үткән ел 22 центнер 36 килограмм арыш җыеп алдык.

Бу участкыга үз вактында тирес түктек. Вакытында тирән итеп сөрдек, яхшылап тырмаладык, яз көне тирес сыекчасы белән тукландырдык. 3 тапкыр утау үткәрдек. Бу чаралар үзләре генә дә безгә әллә никадәр зур файда бирде, тәҗрибә бирде һәм иген уңышын күтәрү өчен бездә чикләнмәгән мөмкинлекләр барлыгын күрсәтте.

Югары уңыш өчен бөтен ел буе көрәшергә кирәк. Агротехника чараларының барысын да тормышка үткәрергә кирәк. Бер генә эшне дә чиратка куярга ярамый. Бөтен эшне план белән алып барганда гына, югары иген уңышы өчен көрәшне яхшы итеп оештырганда гына көткән нәтиҗәгә ирешергә мөмкин.

Авыл хуҗалыгы эшләренең мөһим чараларыннан берсе—кырга тирес чыгаруны, кар тотуны, көл, кош тизәкләре җыюны без вактында үтибез. Үткән елны да без бу чараларның бөтенесен дә үрнәк рәвештә башкарып чыктык. Тунга сөрү планын төгәл үтәдек. Язга чыккач җирне яхшы итеп культивацияләдек. Чүп үләннәрен вактында утап тордык.

Безнең колхозда хезмәт дисциплинасы нык. Колхозчылар үзләренә тапшырылган эшне намус белән үтиләр. Үткән елны бер генә колхозчының да прогул ясамавын колхозда хезмәт дисциплинасының ныгуы белән аңлатырга мөмкин.

Безнең колхоз Алкин авылындагы „Яңа тормыш“ колхозы белән ярышта алдынгылыкны алды. Ярыш договорының үтәлешен язгы чәчү башланыр алдыннан бер тапкыр, чәчү беткәч—икенче тапкыр, урып-җыю төгәлләнгәч—өченче тапкыр тикшердек.

Хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүдә үрнәк күрсәтүче колхозчылар бездә аз түгел. Алар авыл хуҗалыгы эшләренең срогында һәм югары сыйфатлы итеп үтәлүе өчен көрәштә үсәләр.

Алдынгыларның тәҗрибәләрен башкаларга күчерү буенча системалы рәвештә эш алып барабыз. Бригадаларда үткәрелә торган производство киңәшмәләре тәҗрибә уртаклашуның трибуны булып әверелде. Шулай ук стена газетасының да роле зур. Стена газетасы кыр эшләре вактында ике көнгә бер, кыш айларында 5 көнгә бер тапкыр чыга. Һәр номерда тәҗрибәләрне уртаклашу буенча материаллар урнаштырыла. Шуңа күрә дә стена газетасының авторитеты үскәннән-үсә бара, колхозчылар аңа якыннан торып катнашалар.

Кем яхшы эшли—аның доходы арта бара. Мисаль өчен колхозчы Сәхип иптәш Мөбарәкҗанов симьясен алып карыйк. Бу семья 1939 нчы елны 1.300 хезмәт көне эшләде. Бу хезмәт көннәренә ул бөртекле ашлыклата гына да 365 пот доход алды. Моның өстенә шактый күләмдә яшелчә һәм акча алды. Ә безнең колхозда мондый семьялар күп.

Колхозчылар таза һәм культуралы тормышта яшиләр. Сыерсыз бер генә хуҗалык та юк.

Терлекчелекне үрчетү буенча да колхоз шактый алга китте. Колхозда товарлыклы-сөтчелек фермасы, сарык фермасы, ат фермасы бар. Аларда терлекләр саны ел саен арта бара. Без тагын бер ферма—кара төлке фермасы оештырдык.

Фермаларда терлекләрне тәрбияләү эше яхшы. Бер генә терлек тә әрәм булганы юк. Терлекләр өчен азык тулысынча җитәрлек.

Колхозчылар 1940 нчы елда тагын да югарырак иген уңышы алу өчен көрәшәләр. Без гектарыннан 20 центнер иген уңышы алу бурычын билгеләдек. Моңа без ирешербез. Моның өчен бездә бөтен мөмкинлекләр бар.

С. Казыйханов.

Хәсанша колхозының (Мамадыш районы) председателе С. Казыйханов.

И. Галиев фотосы.

ДЕЛКИ СЫРТЫНДА

Гадәттә нинди дә булса киңәшмә яки съездга баручыларга колхоз хисапчылары бер-ике битлек кечкенә генә язу биреп җибәрәләр. Бу язуда киңәшмәгә баручының үзе турында яки гомумән колхоз турында кайбер маглүматлар күрсәтелгән була. Бу иптәш тә кулына шундый язу тоткан. Анда, әлбәттә, „Оборона“ колхозының (Мамадыш районы, Югары Ушма авылы) авыл хуҗалыгы коралларына ремонт ясауны тәмам итүе, тирес чыгару эшен 42 процентка, кош тизәге, көл кебек ашламалар җинауны 52 процентка үтәве кебек саннар, кызыклы фактлар бар һәм ул бик грамоталы кеше тарафыннан язылган. Шулай булса да без күбрәк звеноводның үзе белән сөйләшүне яхшы таптык.

Ул Татнаркомзем бинасы бүлмәләрендә аз гына тартыныбрак сөйли. Регистрация бүлмәсеннән коридорга чыгу белән артына әйләнеп карап, аптырап та киткәли:

— Тукта әле абый, бу ничәнче бүлмә булды сон, монда тагы кирәсем бар бит минем. Номерын карамасаң, биредәге бүлмәләрнең рәтенә төшенеп җитә алмассың,—ди.

Ләкин беренче карауга оялчанрак һәм кыюсызрак күренә торган бу звеновод үз эшенең рәтенә бик яхшы төшенгән. Әгәр дә син тирес түгү яки кар тоту турында сүз ачасың икән, ул инде бу мәсьәләләрдә суда йөзгән балык шикелле. Без аның белән кар тоту турында сөйләшәбез. Ә аның бу турыда сөйләрлек эшләре күп. „Татнаркомзем бүлмәләренең рәтенә төшенә алмассың“ дигән Маһитап Әхметова кар тотуның рәтен берничә еллардан бирле бик яхшы төшенеп килә икән. 1935 нче елдан бирле икенче бригаданың икенче звеносының җитәкчесе булып эшләүче Маһитап иптәш Әхметованың бу турыда сөйләгәннәрен тыңласаң да ярый.

„Оборона“ колхозы кырларында кар ятмый торган урыннар аз түгел. Шуларның берсе—Делки сырты. Маһитап җитәкчелек итә торган звенонның кышкы эшләренең үзәге дә менә шушы Делки сыртында.

Звено члены Нигматҗан Әхмәтҗанов шушы Делки сырты өчен урманнан чыршы ботагы ташый, Газизулла Шәйдуллин шул ук сыртка тезү өчен щитлар үрә, ә Һәдия Хәсәнова, Шәмсенур Җиһаншина, Бикә Әхметова, Бибинур Билалова һәм Һаҗәр Ситдиковалар бу ботакларны, щитларны кар катлавы калынайган саен әле бер урынга, әле икенче урынга күчерәләр. Һәрбер буран артыннан звеноны кар тоту участкысында—Делки сыртында күрәсең. Маһитап бу турыдагы сорауларның берсенә дә аптырап калмый һәм аның биргән җаваплары да нак эше кебек үк бик гади:

— Щитларны ничек тезәсез, аралары күпме кала?

— Атлам саен берне куябыз абый.

— Алай күп куярга щитларыгыз җитәме соң?

—Җитмәсә,—ди ул көлемсерәп,—кар белән кар тота торган гадәт тә бар безнең абый.

— Ничек?

— Башта щит белән, ботаклар белән тотасың да, аннары кар катлавы бераз калынайгач, көрәк белән карның үзен кисеп аласың. Дүрт кисәк карның башларын бер-беренә терәтеп куйсаң, барыбер щит шикелле була ул. Гел щитларга гына таянсаң, аны ничек җиткерәсең абый, без бит колхозда 20 звено.

— Кар тотуның дөрес үткәрелгәнлеген берәр кешенең килеп тикшергәне бармы соң?

— Булмаган кая ул абый. Харитонов үзе безнең белән бергә чыга.

— Кая?

— Басуга—кар тоткан җиргә!

— Ә ул Харитонов кем булып эшли?

— Улмы, ул—безнең колхозның агрономы инде. Иван исемле, шушыннан Казаннан барган агроном. Гел безнең колхозда гына эшли. Түгәрәкне дә шул алып бара. Кичтән кар тоту турында укыта, иртә белән Делки сыртына кар тотарга алып чыга. Әле мин шушы киңәшмәгә китәр алдыннан 23 нче гыйнварда гына Харитоновлар белән бергә щитларны күчердек.

— Бу ничәнче тапкыр күчерүегез була?—дип сорыйбыз без аннан.

— Җиденче тапкыр,—ди ул.

— Тагы ничә тапкыр күчерәсез?

— Яңадан күчермәбез инде абый. Делки сыртында кар тоту шуның белән бетә. Кайбер шәрәрәк урыннарына гына куйгаларбыз.

— Ә аннары?

— Аннары, Бурсык сыртына күчәбез. Ансы инде планнан тыш эшләү була, анда кар тоту планда юк иде дә, шулай да, анда да тотарга булдык. Без бит йөзпотчыларга кушылдык. Аларга кушылгач, Бурсык сыртында да кар тотмый булмас дип уйлаштык.

Шулай юаш кына сөйләп утыра торган бу звеновод үткән ел 19 гектар арышның һәрбер гектарыннан 13,62 центнер (бригада буенча арыш уңышы 11,40 центнер) уңыш алган. Бодай уңышы да бригадага караганда гектар саен 1,60 центнер артык чыккан. Быел исә звено членнары һәрбер гектардан 17,5 центнер уңыш алуны үзләренә бурыч итеп—ярыш шарты итеп куйганнар.

Маһитап звеноның бу вагдәне үтәвенә бик нык ышана:

— Була ул абый, аягыңны алданрак киенсәң, булмый калмый ул, ди.

„Аягыңны алданрак киенсәң“ дигән сүзне аңлатыбрак бирү өчен булса кирәк, яңадан шуңа кайтып:

— Кышкы эшләрне иртәрәк төгәлләүне әйтәм,—кар тоту да, тирес чыгару да, орлык тазарту да—барсы да эш бит алар. Эшне ничаклы иртә бетерсәң, шул чаклы җайлы була ул,—ди.

Ә кышкы агротехника чаралары үткәрүдә Маһитап, чынлап та, нак үзе әйткәнчә, аягын шактый алдан киенгән кыз. Аның звеносы планда каралган 400 йөк тиреснең 307 йөген басуга әллә кайчан ук чыгарган инде.

Хәзергә әле Делки сыртында шахмат шикелле төзелгән щитлардан һәм алар арасына өелгән аппак карлардан башка бер нәрсә дә юк. Анда, хәзергә әле буран уйный, җил сызгыра. Анда бөтен көче белән кыш патшалык итә. Ләкин озакламас, җәй килер, һәм бу җәй Делки сыртында да, шулай ук Бурсык сыртында да матур килер, аеруча ямле килер. Аның җилләре дә кышкы кебек әче, салкын булмас, ә җылы, йомшак булыр. Кем белә, бәлки Маһитап звеносы алдагы җәйдә шушы сыртта үзенә бер югары уңыш даны табар. Бу сыртларның берсендә 30 гектар сортлы арыш, икенчесендә 47 гектар сортлы солы шаулап утырыр. Аларның бу шаулавы югары иген уңышы тавышы булыр.

Ул Казанга, авыл хуҗалыгы алдынгыларының республика киңәшмәсенә килгән. Ул бер яктан киңәшмәдә яңа кешеләр күрү, яңа тәҗрибәләр белән танышу өчен дулкынлана, икенче яктан аның күңелендә Бурсык сырты. Һәм ул еш кына кабатлап ала:

— Делки сыртында эш бетте. Бурсык сыртында да кар тотып кала алсак әй-яй шәп булыр иде,—ди.

Утыра торгач:

— Бу арада бураны да туктап тора әле,—дип ала.

— Нигә алай дисең Маһитап, буран начар нәрсә бит ул,—дибез без.

— Аның безнең өчен яхшы ягы да бар абый. Буран булса, щитлар арасына кар тиз өелә бит.

Шунда ук үзләре белән ярышучы 3 нче звеноны да исенә төшереп куя:

— Моңарчы безнең звено алда бара иде дә, быел ничек булыр инде. Кар тотуда алардан алга чыгуыма нык ышанам югыйсә, шулай да мин Казаннан кайтканчы, алар бездән алга чыкмагайлары дип тә уйлыйм,—ди ул безгә карап.

Нишлисең, ярышучы йөрәк төрле яклап уйлый шул!

Гариф Галиев.

КАЗАН МЕДИЦИНА ИНСТИТУТЫНА 125 ЕЛ

Мединститутның анатомия музеендә ассистент Ф. Н. Камалетдинов II нче курс студентларыннан анатомия буенча зачет ала. Б. Невзоров фотосы.

ЮБИЛЯРГА КОТЛАУЛАР

Кадерле юбилярга—үзенең тарихы медицина тарихыннан аерылмаслык булган Казан Медицина институтына—без, анда тәрбияләнгән кешеләр кайнар сәлам җибәрәбез.

Царизм елларында без анда халыкка мәхәббәт белән карауга, иптәшлеккә һәм дуслыкка өйрәндек. Без үзебезне өйрәтүчеләрнең сөекле исемнәрен ихтирам белән искә алабыз, фәнни тикшеренүләрдә аларның алдынгы идеяләрен дәвам иттерүчеләр булу бәхтенә һәм җаваплылыкка югары бәя бирәбез.

Совет власте елларында фәннең һәм культураның күренекле үзәге булып әверелгән Казан Медицина институтының тагын да үсүен һәм чәчәк атуын чын күңелдән телибез!

Профессор РАЗЕНКОВ, фәннең атказанган эшлеклесе А. ВИШНЕВСКИЙ, фәннәр Академиясенең члек-корреспонденты Б. ЛАВРЕНТЬЕВ, академик А. СПЕРАНСКИЙ.

МОСКВА.

* * *

Данлыклы Казан Мединститутын котлыйм һәм Совет фәне Файдасына аның тагын да алга китүен телим.

ОДЕССА. УССР Верховный Советы депутаты, академик *ФИЛАТОВ.*

* * *

Урта Азия дәүләт университеты профессорлары, укытучылары һәм студентлары исеменнән Казан Медицина институтын данлыклы юбилее белән котлыйм. Ничек эшләргә, Совет фәнен ничек төзергә кирәклеккә сезнең тәҗрибәгездә өйрәнүче яшь туганыгыздан институт коллективына большевистик сәлам тапшырыгыз.

ТАШКЕНТ. *Университет ректоры МУРАВЕЙСКИЙ.*

* * *

Казан Медицина институтын аның тарихи юбилее көнендә чын күңелдән котлыйм. Ватаныбызның хезмәт ияләре файдасына киләчәктә дә уңышлар телим.

ЛЕНИНГРАД. *Профессор ОСИПОВ.*

* * *

Дагыстан Мединститутының профессорлар-укытучылар коллективы һәм студентлары медицина фәненең данлыклы чишмәсен, бөтен дөнья күләмендә исемнәре атаклы булган галимнәр тәрбияләгән Казан Мединститутын 125 еллык юбилее көнендә чын күңелдән котлыйлар. Социалистик ватаныбыз данына, кардәш Татарстан хезмәт ияләре файдасына киләчәктә дә чәчәк ату, фән өлкәсендә яңа казанышлар яулап алуын телибез.

Институтның директоры ШАРОВ, директор урынбасары БАЙРАШЕВСКИЙ, парторг БОРИСКИН, профком КИРЕЕВ.

МАХАЧ КАЛА.

* * *

Свердловск Медицина институты профессорлары исеменнән кардәш ВУЗ ны данлыклы юбилее белән котлыйм.

СВЕРДЛОВСК. *Профессор ГОЛОСОВКЕР.*

* * *

Данлыклы кардәш Казан Медицина институты белән горурланам. Анардан күп кенә күренекле фән эшлеклеләре укып чыктылар. Беренче остазларыма—Миславскийга һәм Полумордвиновка чын күңлемнән рәхмәт белдерәм.

Кадерле юбилярга бөек Советлар иле файдасына киләчәктә дә чәчәк ату телим.

ЛЕНИНГРАД. *Профессор К. БЫКОВ.*

* * *

РСФСР хөкүмәте тарафыннан миңа фәннең атказанган эшлеклесе дигән исем бирелү укытучы, врач, фән работнигы сыйфатында минем өстемдә булган зур җаваплылык хисен көчәйтте.

Мин врачлар кадрлары тәрбияләү өлкәсендә 35 ел буена эшлим. Минем аудитория аркылы берничә мең студент үтте, кайчандыр студентлар скәмияләрендә утырган кешеләр күптән үк инде врачлар, фән работниклары, профессорлар булып әверелделәр. Лекцияләр ясау тәҗрибәм бай булуга карамастан, мин үземә карата элеккечә үк ныклы таләпләр куям. Кафедрага кергәндә мин һәр вакыт үз алдымда яшь, сизгер, тиз аңлаучан аудитория торганлыкны исемдә тотам. Педагог яшьләрнең аңында белемнәргә сусау, фәнгә мәхәббәт тудырырга тиеш. Моның өчен ул үз белемен өзлексез күтәрә барырга тиеш.

Миңа атказанган фән эшлеклесе дигән исем бирелүдән туган зур шатлык алдагы эш өчен яңа көч бирә. Фәнгә һәм үзләренең бөтен тормышларын шуңа багышлаган кешеләргә большевиклар партиясенең дә, Совет хөкүмәтенең дә, халыкның да югары бәя бирүләрен аңлау—илебездәге галимнәр өчен зур таяныч. *Фәннең атказанган эшлеклесе профессор А. МИСЛАВСКИЙ.*

АЛДЫНГЫ МЕДИЦИНА ФӘНЕ ӨЧЕН

Бүген Казан Дәүләт Медицина институты үзенең 125 еллык юбилеен үткәрә. Бу, институтның профессорлары, укытучылары һәм студентлары өчен генә түгел, бәлки республикабызның барлык хезмәт ияләре, бөек Ватаныбызның барлык медицина работниклары өчен зур бәйрәм.

Казан Медицина институты бары тик Октябрь Революциясеннән соң гына, бөек большевиклар партиясе җитәкчелегендә генә үзенең тулы чәчәк атуына ирешә. Хәзер институтта 2.500 студент алдынгы совет фәнен үзләштерә. Элек, Октябрь Революциясенә кадәр, югары уку йортларының ишекләрен дә ачарга хокуклары булмаган эшче, крестьян балалары һәм хезмәтчел интеллигенция балалары хәзер шушы институтта Маркс — Энгельс — Ленин—Сталин таглиматы рухында тәрбияләнәләр, коммунизм төзүчеләр булып хәзерләнәләр. Хәзер институтның фәнни кадрлары зур көч булып үстеләр. Биредә 37 профессор, 28 доцент, 148 ассистент, 60 тан артык аспирант, ординаторлар эшлиләр. Институтның фәнни работниклары арасыннан 30 кешенең фәннәр докторы дигән һәм 50 кешенең фән кандидаты дигән гыйлми дәрәҗәсе бар.

Институт үзенең яшәү дәверендә 10 меңгә якын врач хәзерләп чыгарды, шулардан 5.008 кеше соңгы 22 ел эчендә хәзерләнде.

Советлар Союзының күп кенә фәнни работниклары бүген аеруча зур шатлык кичерәләр. Чөнки алар шушы институтта укыдылар, үзләренең фәнни эшләрен бу институтта башладылар. Академик А. Д. Сперанский, профессор К. М. Быков, фәннең атказанган эшлеклесе А. В. Вишневский, Фәннәр Академиясенең член - корреспонденты В. П. Осипов, фәннең атказанган эшлеклесе, СССР Верховный Советы депутаты В. К. Трутнев, фәннең атказанган эшлеклесе А. Н. Миславский һәм күп кенә башка иптәшләр шушы институтта тәрбияләнеп чыккан кешеләр.

Орденлы Татарстанның хезмәт ияләре карт институтлардан берсе булган Медицина институтының 125 еллыгы көнен гаять зур шатлык һәм горурлык белән каршылыйлар. Институт тарафыннан тәрбияләнгән меңнәрчә яңа врачлар армиясе, большевиклар партиясе җитәкчелегендә, республикабызда сәламәтлек саклау эшен тамырыннан үзгәртте. Әгәр дә 1913 нче елда, элекке Казан губернасында бары тик 88 больница, 379 врач булса, 1938 нче елны больницалар саны 128 гә җитте. Бала тудыру йортлары, ясләләр челтәре киң җәелде. 206 урында акушерлык пункты төзелде. Татарстанда эшләүче 1.721 врач Казан Медицина институтында тәрбияләнделәр. Медицина белемнәре белән коралланган хәлдә, марксизм-ленинизмны тирән өйрәнеп, алар, халыкның киң массасы арасына культураны алып баралар, кешенең сәламәтлеге өчен культуралы, бәхетле тормыш өчен армый-талмый көрәшәләр. Менә шуның өчен дә республикабызның хезмәт ияләре совет медицина эшлеклеләрен яраталар, аларны игтибар һәм кайгыртучанлык белән чолгап алалар. Хезмәт ияләре профессорлардан Трутнев, Агафонов, Адо, Соколов һәм башка иптәшләрне Верховный Советларга һәм хезмәт ияләренең җирле Советларына депутат итеп сайлап, үзләренең аларга булган ышанычларын тагын бер тапкыр күрсәттеләр.

Институтның студентлар коллективы—ул, зур һәм бердәм коллектив. Студентлар төрле яктан белемле, культуралы һәм Ленин—Сталин типындагы эшлеклеләр булырга омтылалар. Алар фәнне кызыксынып өйрәнү белән бергә, зур җәмагат һәм фәнни эш алып баралар. Хезмәт ияләренең җирле Советларына сайлаулар кампаниесендә студентлардан 500 кеше доверенныйлар, сайлау комиссияләренең председательләре, членнары булып, агитаторлар булып эшләделәр.

Студентлар сугыш белемен аеруча кызыксыну белән өйрәнәләр. 1.600 кеше Осоавиахим члены булып тора. Алар арасында 1.225 кеше ПВХО, 334 кеше „Ворошиловча атучы" значокларын күкрәкләрендә зур горурлык белән йөртәләр. Бары тик 1939 нчы елны гына да 12 пулеметчик, 51 мотоциклист, 24 парошютчы хәзерләнде.

Марксизм-ленинизм фәне буенча үткән экзаменнар гүзәл нәтиҗәләр бирде. Икенче курста укучы 550 студенттан экзаменны 222 кеше отлично һәм 229 кеше яхшы билгеләренә тапшырдылар. Бу үзе генә дә студентларның югары белемле булу өчен чынчыннан омтылуларын ачык күрсәтә.

Медицина институты үзенең юбилеенә гаять зур уңышлар белән килде. Ләкин институт алдында тагын да катлаулырак, җаваплырак бурычлар тора. Совет врачлары дөньяда иң алдынгы, иң культуралы, югары белемле булырга тиешләр. Моның өчен Совет хөкүмәте һәм бөек большевиклар партиясе бөтен шартларны тудырдылар.



Гомуми биология кафедрасы студентларыннан бер группа практик занятиедә. И. Попков фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

ЮБИЛЯРГА КОТЛАУЛАР

Медицина фәнен үстерүче иң борынгы һәм иң матур бакчалардан берсен—Казан Медицина институтын—аның 125 еллык юбилее белән кайнар рәвештә котлыйбыз. Казан университетының медицина факультеты бик күп санда зур врачлар, галимнәр тәрбияләп чыгарды. Бу матур бакчада үсеп чыккан ул галимнәр рус медицинасы тарихында якты эз калдырдылар, калдыралар һәм киләчәктә дә калдырырлар.

Институтның барлык профессорларына, укытучыларына, студентларына сәлам һәм аларның алдагы эшләре өчен яңа уңышлыклар теләп калабыз.

Профессор ЛУРИЯ („Совет Медицинасы" журналы редакторы).

* * *

Элек Казан Медицина институтында тәрбияләнгән һәм хәзерге көндә Сталинград шәһәренең Медицина институтында эшләүче работниклар—без үзебезнең бишегебез булган Казан Медицина институтын—аның 125 еллык бәйрәме белән котлыйбыз. Безне тәрбияләгән Казан Медицина институтында алган тәҗрибәләребезне һәм яхшы традицияләрне эштә нык кулланып, яшь институтны оештыруга һәм ныгытуга барлык көчебезне, белемнәребезне бирүебез турында сезгә рапорт җибәрүебез өчен үзебезне бәхетле саныйбыз.

Бөек Сталин эпохасына лаеклы врачлар хәзерләп чыгару эшендә сезгә яңа уңышлыклар теләп калабыз.

Бренштейн, Эпштейн, Вольфсон, Лифшиц, Колосов, Никогосян, Милосердева, Григорьев, Абрамзон, Куницын, Ткаченко һәм башкалар.

КАНЦЕЛЯРИЕДӘ

27 нче сентябрьдә Казан Медицина институтының канцеляриесендә аеруча бер җанлылык сизелде. Кешеләр шат йөз белән берсен-берсе сәламлиләр, өзлексез телефон шалтырый, институт исменә бер туктаусыз телеграммалар явып тора.

Директор секретаренең өстәлендә телеграммалар тау булып өелеп яталар. Болар СССР ның төрле почмакларыннан институтка, аның 125 еллык юбилее уңае белән җибәрелгән котлау телеграммалары. Монда Кырымнан да, Харьковтан да, Киевтән дә, Ташкенттан да, Москвадан да, Бакудан да, Ленинградтан да, тагын бик күп шәһәрләрдән дә бар.

Карт белем учагы булган Казан Медицина институтыннан тәрбияләнеп чыккан белгечләр киң илебезнең төрле почмакларында армыйталмый эшләп яталар, алар хезмәт иясе халыкка медицина ярдәме күрсәтәләр һәм совет медицинасының данын күтәрәләр. Менә шулар, барсы да дип әйтерлек, үзләрен укытып, тәрбияләп чыгарган институт исменә — үзләренең бишекләре исменә — җылы сүзләр белән тулган котлау телеграммалары җибәрәләр, институтның алдагы эшенә уңышлыклар телиләр.

Ул арада юбилей көннәрен үткәрү өчен Казанга килергә чыккан кешеләрдән телеграммалар җава башлый.

Фәннәр академиясенең член-корреспанденты профессор Лаврентьев.

СССР Верховный Советы депутаты, фәннең атказанган эшлеклесе профессор Трутнев.

Академик Сперанский.

Болар бик күпләр.

Ул арада булмый,ишек кинәт ачылып китә, анда беренче кунак булып, Астраханнан килгән профессор Непряхин күренә... Гыйлми эшчеләр, профессорлар берберсе белән дусларча исәнләшәләр, кулларын кысышалар, хәлэхвәл сорашалар, эш турында кыскача әңгәмә ясап алалар.

Институтның барлык нервларын үзендә җыйган бу бүлмәләрдә бүген аеруча бер эшлекле җанлылык, тантаналы һава хөкем сөрә. Бу аңлашыла да. Чөнки Совет медицинасының чәчәк атуы өчен күп көч куйган данлыклы белем учагы — Казан Медицина институты үзенең 125 еллык бәйрәмен итә. *Ф.*

ДАНЛЫКЛЫ ЮБИЛЕЙ

Доцент М. В. НЕЖДАНОВ.
Казан Дәүләт Медицина институты директоры, медицина фәннәре кандидаты

Моннан 125 ел элек—1814 нче елны Казан университетының медицина факультеты төзелде. 1930 нчы елны ул үзенә аерым Медицина институтына әйләндерелде. Ул вакытта (1814 нче елда) Казан бары 25 мең кешесе булган кечкенә генә шәһәр иде. Монда ачылган университет, Москва университетыннан кала икенче университет булды һәм Себернең, Уралның, Волга буеның гаять зур территориясенә һәм бөтен көнчыгышка хезмәт итте. Ул вакытта университетның һәм аның медицина факультетының төп бурычы көнчыгышта патша хөкүмәтенең колониаль политикасын үткәрү өчен дворяннардан һәм алпавытлардан патша самодержавиесенә турылыклы чиновниклар хәзерләүдән гыйбарәт иде. Медицина факультеты ачылганда аның үзенең 3 профессоры, бер адъюнкты һәм 2 студенты бар иде.

Устав буенча 6 кафедро төзелде: анатомия, физиология һәм суд медицинасы кафедрасы, патология, терапия һәм клиника кафедрасы; врачлык әйберләрен өйрәнү, фармация һәм медицина теле кафедрасы; хирургия кафедрасы, акушерлык кафедрасы һәм терлекләрне дәвалау кафедрасы.

Кандидатлар булмаганлыктан күп кенә кафедралар озак вакытлар эшләмәделәр һәм бары тик чит илләрдән галимнәр чакырылгач кына эшли башладылар. Казанның беренче профессорларының күпчелеге немецләр иде. Лекцияләр күп вакытта латын телендә, кайбер вакытта немец яки француз телендә укылдылар. Студентлар бу телләрне белмәделәр, дәреслекләр бөтенләй диярлек юк иде һәм укыла торган материалны үзләштерү проблемасы чиктән тыш авыр иде. Медицина факультетын гаять авыр шартларда оештырырга туры килде. Аның уку биналары барсы да диярлек хәзерге иске клиника территориясендәге „типография йорты"нда урнашканнар иде.

Анатомия кабинеты типография йортының бер бүлмәсенә урнашкан иде, аның укыту коллекциясе бер яшь баланың скелетыннан, дүрт аяклы этәч скелетыннан, ике үрдәк скелетыннан һәм кеше скелетының таркау сөякләреннән гыйбарәт иде. Терапевтика клиникасының шул ук типография йортында ике бүлмәгә урнаштырылган 4 койкасы бар иде. Акушерлык фәне рәсемнәр буенча бары тик теоретик яктан гына укытылды. Профессорлар бер юлы берничә кафедрага җитәкчелек иттеләр. Мәсәлән, талантлы галим профессор К. Ф. Фукс анатомия кафедрасын һәм патология һәм терапия кафедрасын алып барды. Фармация профессоры Лептовский хирургиядән, терапиядән, физиологиядән, суд медицинасыннан укытты, һәм соңыннан акушерлык профессоры итеп билгеләнде.

Университет һәм аның медицина факультеты озак вакытлар буена шундый авыр хәлдә яшәделәр, тик 1828 нче елны гына бина мәсьәләсе бераз яхшыра төште. Типография йорты бөтенләе белән медицина факультетына бирелде һәм анда өч бүлек урнаштырылды—хирургия бүлегендә 14 койка, терапевтика бүлегендә 16 койка һәм акушерлык бүлегендә 6 койка булды.

1837 нче елны Воронихин шәкерте талантлы архитектор Коринфский проекты буенча анатомия корпусын төзү тәмам булды. Казан анатомия театры хәзердә дә архитектурада ватан классицизмында үзенә бер төрле бердән-бер памятник булып тора.

1840 нчы елны клиниканы төзү тәмам булды, хәзер ул „иске клиника" дип йөртелә. 1840 нчы елны медицина факультеты составында инде 9 профессор, 2 доцент һәм 4 ассистент белән 10 кафедра булды. Бу вакытта студентлар инде 50 кешегә җитте.

Медицина факультеты шушы хәлендә 1863 нче елга кадәр яшәде. 1863 нче елны күп кенә яңа кафедралар: физиология, физиологик химия, гистология, патологик анатомия, психиатрия, күз авырулары кафедралары төзелде, шәһәр больницалары базасында госпиталь клиникалары оештырылды. 1865 нче елны инде 17 кафедра булды һәм студентлар саны 203 кешегә җитте. Медицина факультеты бик акрын үсте һәм 1917 нче елны гына 23 кафедра булып, аларда 24 профессор һәм 34 ассистент эшләде. Студентлар саны 837 кешегә җитте. Студентларның составы социаль чыгыш ягыннан түбәндәгечә иде: дворян һәм эре чиновник балалары 37 процент, руханыйлар балалары 9 процент, почетлы гражданнар һәм купецлар 11 процент, крестьяннәр-кулаклар 17 процент һәм башкалар 24 процент. Бу саннардан күренгәнчә, хезмәт халкы вәкилләре югары медицина уку йортларына керә алмаганнар, һәм югары белем алу бик аз сандагы кешеләргә генә мөмкин булган, нигездә исә өстен сыйныфларның вәкилләре генә укыганнар. Укучылар арасында татарлар, чувашлар һәм Волга буенда яшәүче башка милләт халыклары бик аз булган. 100 ел эчендә төрек-татар милләтеннән бары 19 врач хәзерләп чыгарылган.

Бөек Октябрь Социалистик Революция генә илебездәге хезмәт ияләре өчен югары уку йортларының ишекләрен киң итеп ачты. Бөек Ленин—Сталин партиясе җитәкчелегендә Казан Медицина институты бик нык үсте.

Медицина институтында укучыларның социаль составы тамырдан үзгәрде. Укыту эше фәннең соңгы казанышлары нигезендә бөтенләй яңа баштан үзгәртеп корылды. Казан Медицина институты хәзерләп чыгара торган врачлар Маркс—Энгельс—Ленин—Сталин таглиматы рухында тәрбияләнгәннәр, коммунистлар партиясенә һәм коммунизм төзелеше эшенә чын күңелдән бирелгәннәр.

Казан Медицина институты үзенең 125 еллыгына килгәндә социалистик Ватаныбыздагы зур югары уку йортларының берсе булып әверелде. Хәзер институтның 49 кафедрасы бар, аларда 37 профессор, 28 доцент һәм 148 ассистент, 60 тан артык аспирант һәм ординатор эшли. Институтның фәнни работникларыннан 30 кешенең фәннәр докторы дигән галимлек дәрәҗәсе һәм 50 кешенең фәннәр кандидаты дигән галимлек дәрәҗәсе бар. Институтта клиник укыту эше 1.350 койкада алып барыла (медицина факультеты ачылганда 6 койка бар иде). Шулардан 800 койка медицина институтының үз клиникаларында.

Институт үзенең яшәү чорында 10 меңгә якын врач хәзерләп чыгарды. Шуннан 5.008 кеше Совет власте яшәгән 22 ел вакыт эчендә чыгарылды, бу бөек Октябрь революциясенә кадәрге 103 ел эчендә чыгарылганнан күбрәк.

Медицина институты составында 3 факультет: дәвалау-профилактика, санитария-гигиена һәм педиатрия факультетлары бар, аларда 2.500 дән артык кеше укый.

Совет власте елларында студентларның социаль һәм милли составы тымрыннан үзгәрде: дворяннарны, алпавытларны һәм чиновникларны эшче, крестьян һәм хезмәтчел интеллигенция балалары алмаштырды. Октябрь революциясенә кадәр 100 ел эчендә медицина факультетын төрек-татар милләтеннән 19 врач тәмам иткән булса, 1928 нче елдан 1938 нче елга кадәрге чор эчендә генә дә медицина институты татарлардан 491 кешене, чувашлардан 134 кешене, марийлардан, удмурдлардан һәм мордвалардан 52 кешене врач итеп хәзерләп чыгарды.

Казан Медицина институты хезмәтләре белән Советлар Союзында гына түгел, бәлки чит илләрдә дә атаклы булган талантлы галимнәрне тәрбияләде. Болар исәбенә А. И. Фрезе, В. М. Бехтерев, Л. О. Даркшевич, П. Ф. Лесгафт, Е. Ф. Аристов, К. А. Арнштейн, Н. А. Миславский, Н. О. Ковалевский, Е. В. Адамюк, А. Г. Ге, Н. А. Геркен, С. С. Зиминицкий, В. С. Груздев һәм күп кенә башкалар керәләр, аларның барсын да кыска гына мәкаләдә санап бетерү мөмкин түгел.

Казан Медицина институты Совет власте елларында Советлар Союзының югары уку йортларына һәм фәнни тикшеренү учреждениеләренә 55 профессор бирде.

Совет медицинасының күрнекле вәкилләре: академик А. Д. Сперанский, фәннәр академиясе член-корреспонденты Б. И. Лаврентьев, профессор К. М. Быков, фәннең атказанган эшлеклесе А. В. Вишневский, фәннәр академиясе член-корреспонденты В. П. Осипов һәм күп кенә башкалар Казан Медицина институтында тәрбия алдылар.

Коммунистик партиябезнең һәм Совет хөкүмәтенең өзлексез кайгыртучанлык күрсәтүләре нәтиҗәсендә, югары квалификацияле профессор—укытучылар составы белән тәэмин ителгән һәм яхшы җиһазландырылган кафедралары, лабораторияләре, клиникалары һәм кабинетлары булган Казан Медицина институты, чыгарылган врачларның саны һәм сыйфаты ягыннан гына түгел, бәлки фәнни продукциясе ягыннан да, бөтен Советлар Союзындагы медицина вузлары өчен фәнни укытучылар кадрлары үстерү һәм хәзерләү ягыннан да Советлар Союзында мактаулы урын алып тора.

Казан Медицина институтының коллективы үз эшендә, бөек гүзәл Ватаныбыздагы барлык галимнәр кебек үк, сталинчыл бишьеллыклар чоры белән, Сталин Конституциясе белән, алдынгы фән тудыру, коммунистик җәмгыят төзү турында Сталин күрсәтмәләре белән рухланган.

Бөек коммунистик партиябез җитәкчелегендә, бөтен дөнья хезмәт ияләре юлбашчысы һәм остазы иптәш Сталин җитәкчелегендә, Казан Медицина институты киләчәктә дә совет халкының сәламәтлеген саклау постында нык торыр һәм Совет фәне байрагын югары тотар.

Чит илләрдә

ЛИТВА БЕЛӘН СССР АРАСЫНДА ЭКОНОМИК МӨНАСӘБӘТЛӘР

КАУНАС, 26 гыйнвар. (ТАСС). „Лиетувос айдас“ газетасы үзенең „Советлар Союзы белән экономик яктан бергәләп эшләү“ дигән баш мәкаләсендә болай яза: „СССР белән без иң нык дуслык җепләре белән бәйләнгәнбез. Безнең белән булган экономик мөнасәбәтләрдә СССР беренче урыннарның берсен алып тора. Һәр ике дәүләт арасында экономик мөнасәбәтләрне киңәйтү, мәгълүм ки, әле, СССР белән Литва арасында үзара ярдәмләшү договорына кул куелган моментта ук билгеләнгән иде. Чынбарлык һәр ике ил арасында экономик яктан бергәләп эш итүне үстерүгә ярдәм итә. Советлар Союзы чималга иң бай булган илләрнең берсе, һәм Литва бирәдә үзенең яш промышленносте өчен һәм киң куллану өчен кирәк булганның күбесен таба ала. Советлар Союзында металлар, нефть һәм башка продуктлар җитештерү көчле рәвештә үсте. СССР да хәзерләнгән бик күп авыл хуҗалыгы машиналары безнең авыл хуҗалыгы өчен кирәк. Индустрияләштерү һәм техника өлкәсендә СССР ның казанышлары шул кадәр популәр ки, алар турында сөйләп торуның да кирәге юк. Менә болар барсы да Литваның Советлар Союзы белән экономик яктан бергәләп эш алып баруы өчен киң мөмкинлекләр ача.

Бөек күрше белән экономик мөнасәбәтләребез моңа кадәр нормаль рәвештә алга барды. Хәзер бу мөнасәбәтләр тагын да күбрәк киңәя ала. Литва—зур ил түгел, ләкин ул Советлар Союзына нәрсә дә булса тәкъдим итә ала. Литва белән Советлар Союзы арасындагы мөнасәбәтләр һәр вакыт үзара бер-береңне аңлауга һәм дуслыкка нигезләнеп килде. Бу хәл һәр ике ил арасында экономик яктан бергәләп эш алып баруны тагын да киңәйтергә булышлык итә, дип уйларга кирәк. Бу эш Литвага, Европада сугыш нәтиҗәсендә килеп чыккан экономик кыенлыкларны уңышлы рәвештә җиңү мөмкинлеген бирер иде“.

АКШ БЕЛӘН АНГЛИЯ АРАСЫНДА КОНФЛИКТ

НЬЮ-ЙОРК, 25 гыйнвар. (ТАСС). Юнайтед Пресс агентлыгының хәбәр итүенә караганда, почта эшләре министрлегенең вәкиле Ламиэль, вәкилләр палатасындагы чыгышында, англичаннарның Америка почтасын басып алулары Германиягә почта илтүгә комачаулый, дип белдергән. Ламиэль, үзенең фикеренчә, дәүләт департаментының протестлары Англияне үзенең политикасын үзгәртергә мәҗбүр итмәячәк, дигән.

НЬЮ-ЙОРК, 25 гыйнвар. (ТАСС). Скриппс Говард газета трестының Вашингтон хәбәрчесе Людуэл Денни, АКШ белән Англия арасындагы конфликтның кискенләшүе турында яза. Денни,— Америка почтасын йөртү эшенә, шулай ук АКШ ның кораблар йөртүенә һәм экспортына Англиянең катнашуына каршы Америка гражданнары торган саен ешрак рәвештә протест белдерәләр, ди. Хөкүмәт, бигрәк тә алда торган президент сайлаулар уңае белән, бу протестларга игътибар бирмичә кала алмый. Аннан соң Денни, әгәр дә англичаннар Американың җәмәгатьчелек фикеренә игътибар итмәүне дәвам иттерсәләр, ул вакытта бу хәл Америка хөкүмәтенең Англиягә һәм Франциягә ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән политикасын өзәргә мөмкин, дип кисәтә.

Денни аннан соң болай яза:— Хөкүмәт Англиянең позициясе уңае белән борчыла һәм Американың нотасын кире кагу гаҗәп дәрәҗәдә начар эш булып тора дип уйлый. Бигрәк тә, нейтралитет турындагы законны Англиягә һәм Франциягә ярдәм күрсәтү теләге белән яңадан карау эшендә хөкүмәтнең гаять зур хезмәтләрен исәпкә алганда, бу начар эш булып тора. Вашингтонда Англияне яклаучы даирәләр ничек кенә гаҗәпләнсәләр дә, хөкүмәт Англиягә каршы репрессив җавап чаралары куллану мәсьәләсен карый булса кирәк. Сенатта изоляционнистлар блогы инде Англиянең коралланган сәүдә корабларын Америка портларына керүне тыюны таләп итә.

ЛОНДОН, 26 гыйнвар. (ТАСС). Англиянең экономик сугыш министрлеге, сугыш башланганнан алып 12 нче гыйнварга кадәр, Англиянең диңгез контроле АКШ тан Германиягә җибәрелгән 6 мең хат һәм 50 мең посылканы тоткан, дип хәбәр итә. Бик күп хатларда чеклар, вексельләр һәм акчалар булган. Шушы чор эчендә Англия властьлары барлыгы: 5.270 мең герман маркасы, 9.900 доллар һәм 17.800 фунт стерлингны конфискациягә алганнар, шулай ук 426 мең долларлык чеклар һәм вексельләр конфискациягә алынган. Экономик сугыш министрлеге вәкиленең хәбәр итүенә караганда, АКШ тан Германиягә азык посылкалары җибәрү гаять зур күләмнәргә барып җиткән. Англия властьлары бу посылкаларның барсын да контрабанда дип карыйлар һәм аларны конфискациягә алалар.

Браудерга карата чыгарылган хөкем карарына каршы протестлар

НЬЮ-ЙОРК, 26 гыйнвар. (ТАСС). Юнайтед Пресс агентлыгы хәбәрчесенең Мексикодан (Мексиканың башкаласыннан) хәбәр итүенә караганда, Мексика компартиясе Үзәк Комитетының пленумы Рузвельтка телеграмма җибәргән. Бу телеграммада Америка компартиясе Үзәк Комитеты секретаре Браудерга карата чыгарылган хөкем карары уңае белән ачу белдерелә. Мексика компартиясенең җитәкчесе Карильо үзенең речендә Американың „АКШ эчендә миллионнарча эшсезләр булган вакытта, Англиягә һәм Франциягә ярдәм күрсәтү өчен Армиягә һәм флотка гаять зур акчалар тотучы“ даирәләренә каршы чыкты.

„Дейли Уоркер“ газетасының Мексикодан алып хәбәр итүенә караганда, Мексика компартиясенең Үзәк Комитеты АКШ компартиясенә телеграмма белән мөрәҗәгать иткән. Бу телеграммада ул Браудерга карата чыгарылган хөкем карары уңае белән ачу белдерә һәм империалистик сугышка каршы Американың барлык халыкларының бердәм хәрәкәтен оештырырга хәзер торуын белдерә.

Газета, Куба компартиясенең дә шулай ук Браудерга карата чыгарылган хөкем карарына каршы протест белдергәнлеген хәбәр итә.

АНГЛИЯНЕҢ БЕЛДЕРҮЕН ГЕРМАНИЯНЕҢ ЮККА ЧЫГАРУЫ

БЕРЛИН, 26 гыйнвар. (ТАСС). Германия информация бюросы, Германиянең, имештер, автомобиль экспортын чикләве турында Англия радиосы тарафыннан бирелгән белдерүне юкка чыгара. Юкка чыгаруда, Германиянең, киресенчә, үз автомобильләрен читкә чыгару белән кызыксынуы турында аеруча күрсәтелеп үтелә. Чит ил заказларын теләсә нинди вакытта үтәү өчен Германиянең автомобиль промышленностының җитәрлек мөмкинлекләре бар. Илдә автомобильләр һәм мотоцикларның запасы зур булу моны ачык күрсәтә.

КӨНБАТЫШ ЕВРОПА СУГЫШЫ

БЕРЛИН, 26 гыйнвар. (ТАСС). Германия армиясенең верховный командованиесе тарафыннан бирелгән хәбәргә караганда, Англиянең разведка самолеты Рур өлкәсе өстендә очарга маташканда Дуйсбург районында бәреп төшерелгән.

БЕРЛИН, 25 гыйнвар. (ТАСС). Германия информация бюросы, Англиянең Киркуолл дигән контроль портында, шартлау булу аркасында, Даниянең „Денмарк“ исемле танкеры баткан. Шулай итеп, нейтраль илләрнең кораблары Англиянең контроль портларына англичаннар тарафыннан китерелгән вакытта, хәтта шул портларда да куркыныч астында булалар.

Англия ярлары буенда корабларның һәлакәткә очрау хәлләре ешайганлыктан, Англия властьлары барлык порт шәһәрләрендә махсус коткару командалары төзергә тәкъдим иттеләр. Бу факт һәм, шулай ук, Ливерпуль портының вакытлы рәвештә ябылуы, диңгездәге сугыш нәтиҗәләре турында Англиянең мәгълүм белдерүләрендә гәүдәләнә торган оптимизмны Британия адмиралтействосының уртаклашмауын күрсәтәләр.

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

(ТАСС хәбәрләреннән)

Көньяк Кытайда

Гуандун провинциясенең үзәк өлешендә кытай гаскәрләре японнарның Хуасяндәге (Кантоннан төньякта) позицияләренә атака ясадылар. Сугыш нәтиҗәсендә японнар гарнизоны Гаотанга (Кантоннан төньяк-көнбатышка таба 30 километрда) чигенергә мәҗбүр булды. Моңа кадәр хәбәр ителгәнчә, 19 нчы гыйнварда кытай частьләре Цзэнчэнгә (Кантоннан көнчыгышта) бәреп кергәннәр иде. Шәһәрнең урамнарында сугышлар дәвам итте. Ләкин японнар, Цзэнчэнгә зур күләмдә өстәмә көчләр китереп, кытай гаскәрләрен шәһәрдән чыгарга мәҗбүр иттеләр. Кантоннан төньякта кытай гаскәрләре японнарның Шицзинь дигән җирдәге (Кантоннан төньякка таба 20 километрда) позицияләрен алдылар, ләкин, японнарга өстәмә көчләр килгәннән соң, үзләренең элекке позицияләренә чигенделәр.

Гуанси провинциясенең көньяк өлешендә, Наньниннан көньякта, кытай гаскәрләре соңгы көннәрдә японнардан күп кенә әһәмиятле пунктларны сугышып алдылар.

Үзәк Кытайда

Линбу станциясе (Сяошаньнан көньякка таба 18 километрда) районында 25 нче гыйнварда каты сугыш булды. Япон гаскәрләре, 500 гә якын кешеләрен югалтып, Сяошаньга чигенделәр. Япон гаскәрләренең 1.000 гә якын кешедән торган колоннасы Сяошаньнан көньяк-көнчыгыш юнәлештә флангыдан хәрәкәт башлаган һәм Шаосинга (Сяошаньнан 40 километрда) килеп җиткән, дигән хәбәрләр бар. Кичә төн уртасына кадәр анда каты сугыш дәвам иткән.

Хубэй провинциясенең төньягында, Суйчжоу районында, шулай ук каты сугышлар дәвам итә. Япон частьләре, зур югалтулар биреп, Суйчжоуга таба чигенәләр. Японнарның чигенеп баручы частьләреннән берсе Суйчжоудан көньяк-көнчыгышка таба 15 километрда кытай гаскәрләре тарафыннан чолганып алынды. Гаочэннан көньяк юнәлештә һөҗүм итүче кытай частьләре 23 нче гыйнварда 1.000 японлыны юкка чыгардылар.

Хэнань провинциясенең көньяк өлешендә курчак властьлар гаскәрләренең 200 кешелек отряды баш күтәргән. Баш күтәрүчеләр кытайның милли хөкүмәте ягына чыкканнар.

Төньяк Кытайда

Шаньдун провинциясендә кытай гаскәрләре японнарның Гаоми шәһәрендәге (Циндаодан төньяк-көнбатышта) гарнизонына атака ясадылар. Чолганышта калган гарнизонга ярдәмгә япон командованиесе мең ярымнан артык солдат җибәргән. Шуңа да карамастан, японнар отряды Гаоминың көньяк-көнбатыш бистәләрендә кытай гаскәрләре тарафыннан тар-мар ителде. Японнарның 700 дән артык кешеләре үтерелде һәм яраланды.

Шаньси провинциясенең көньяк-көнчыгыш өлешендә, Чжанцзы—Хугуань районында, кытай һәм япон гаскәрләре арасында сугышлар дәвам итә.

АКШ ТА НЕГРЛАРНЫҢ ХӘЛЕ

НЬЮ-ЙОРК, 26 гыйнвар. (ТАСС). Негрларны коллыктан азат итү өчен көрәш эпохасыннан алып эшләнгән „Линкольн Иллинойста“ дигән яңа кино-фильмгә 23 нче гыйнварда Вашингтонда просмотр булды. Ләкин бу фильм бара торган кино-театрга негрлар кертелми. Кино-театр бинасы янында негрларның һәм ак тәнле кешеләрнең пикетлары негр халкын шундый мәсхәрәләүгә каршы протест белдерәләр. Барлык көньяк штатларда, шулай ук төньяктагы күп штатларда негрлар бары тик үзләре өчен билгеләнгән театрларга һәм рестораннарга керү белән генә чикләнергә мәҗбүрләр.

БЕЛДЕРҮ

Бүген, кич 6 сәгаттә, язучыларның Г. Тукай исемендәге кабинетында шагыйрьләр секциясенең җыелышы була. Җыелышта „Евгений Онегин“ ның тәрҗемәсе турында доклад һәм фикер алышулар булачак.

ДӘҮЛӘТНЕҢ ИКЕНЧЕ БИШЬЕЛЛЫК ЗАЕМЫ

(ДҮРТЕНЧЕ ЕЛ ЧЫГАРЫЛЫШЫ)

Оттырышсыз чыгарылыш буенча отышларның унdүртенче тиражының белешмә таблицасы

Тираж 1940 нчы ел, 17 һәм 18 нче гыйнварда Чкалов шәһәрендә үткәрелде.
Тиражда 196. 420.000 сумлык 1.210.000 отыш уйналды.
Таблицада 100 сумлык облигациягә чыккан отышларның күләме күрсәтелә.
Күрсәтелгән отыш сумасы эченә облигациянең үз бәясе дә керә.
Отышлар түбәндәге серия һәм облигация номерларына чыкты:

Серия №№	Облигация №№	Отышның күләме (сумнар белән)
00247	1—50	150
00303	1—50	150
00516	04*)	500
00623	1—50	150
00684	1—50	150
00747	1—50	200
00756	41*)	500
01255	12*)	500
01570	1—50	150
01820	29*)	500
01823	1—50	150
02083	1—50	150
02108	1—50	150
02267	1—50	150
02930	1—50	150
03044	1—50	200
03207	1—50	150
03361	23*)	500
03516	49*)	500
03531	25*)	500
04054	1—50	150
04248	1—50	150
04640	1—50	200
04725	1—50	150
04825	1—50	150
04830	20*)	500
04990	1—50	200
05246	1—50	150
05252	1—50	150
05306	04*)	500
05350	1—50	150
05695	1—50	150
05843	1—50	150
05900	1—50	200
06038	34*)	1.000
06195	1—50	150
06245	49*)	500
06314	17*)	500
06669	29*)	500
06690	19*)	500

Серия №№	Облигация №№	Отышның күләме (сумнар белән)
06708	09*)	500
06756	48*)	500
07069	1—50	200
07411	1—50	200
07447	06*)	500
07459	27*)	500
07470	1—50	200
07497	1—50	150
07674	1—50	150
07894	36*)	500
08056	1—50	200
08084	1—50	200
08329	47*)	500
08465	29*)	500
08775	04*)	500
09291	1—50	200
09317	23*)	500
09387	03*)	500
10123	1—50	200
10548	49*)	500
10555	39*)	500
10655	37*)	500
10694	1—50	150
11016	1—50	150
11108	1—50	150
11367	1—50	150
11482	36*)	500
11558	49*)	500
11623	1—50	200
11655	42*)	500
11853	1—50	150
11935	1—50	200
12117	12*)	500
12885	34*)	500
13148	1—50	200
13413	1—50	200
13553	47*)	500
13843	1—50	150
13867	03*)	500
13908	22*)	500
13973	49*)	500

Серия №№	Облигация №№	Отышның күләме (сумнар белән)
14097	1—50	150
14215	1—50	150
14274	1—50	150
14454	1—50	150
14508	1—50	200
14670	1—50	150
15130	1—50	200
15517	47*)	1.000
15574	38*)	500
15577	1—50	150
15701	29*)	500
15731	41*)	500
15833	17*)	1.000
15938	1—50	150
16150	1—50	150
16238	30*)	500
16600	05*)	1.000
16650	07*)	500
16698	16*)	500
17087	19*)	500
17165	29*)	500
17325	1—50	150
17384	1—50	150
17501	06*)	500
17565	1—50	150
17933	33*)	3.000
18193	21*)	500
18320	41*)	1.000
18517	05*)	500
18525	34*)	500
19050	1—50	200
19055	50*)	500
19131	1—50	150
19232	1—50	150
19367	1—50	200
19373	1—50	150
19522	09*)	500
19540	1—50	150
19643	39*)	500
19957	1—50	150

*) Бу серия облигацияләрнең калган 49 номеры һәрберсе 150 шәр сум отты.

АУЧЫЛАР ҺӘМ БАЛЫКЧЫЛАР ИГЪТИБАРЫНА!

31 нче гыйнвар, кич 6 сәгатьтә Физкультура һәм Спорт Республика Комитетының спорт залында (Бауман урамы 76)

АУЧЫЛАР ҺӘМ БАЛЫКЧЫЛАР КОНФЕРЕНЦИЯСЕ ҮТКӘРЕЛӘ

КӨН ТӘРТИБЕ: 1. Аучылар секциясенең 1939 нчы елгы эше һәм 1940 нчы елда аучылык-балыкчылык спортын җәелдерү буенча алда торган бурычлар турында. 2. Аучылык свидетельстволары бирү турында. 3. Аучылар секциясенә сайлаулар. 4. Төрлеләр.

157—1 Физкультура һәм Спорт Эшләре Шәһәр Комитеты.

Барлык колхозлар, колхозчылар һәм хезмәт иясе ялгыз хуҗалыкчылар игътибарына!

Казан Шәһәре Базарлары Идарәсе

Барлык колхозларны, колхозчыларны һәм хезмәт иясе ялгыз хуҗалыкчыларны,—үзләреннән арткан ит, сөт, май, суелган кош-корт, орлык продуктлар, бәрәңге, төрле яшелчәләр һәм башкалар кебек авыл хуҗалыгы продуктларын Казан шәһәре халкына сату өчен, Казан Шәһәре базарларына чакыра.

Сәүдә өчен кирәкле барлык инвентарь, махсус санитария киеме, лареклар һәм биналар бирелә. Базарларда ит-сөт тикшерү станцияләре һәм продуктларны саклау урыннары бар.

Колхозлардан оештырылган тәртиптә килгән колхозчыларга һәм хезмәт иясе ялгыз хуҗалыкчыларга карата, базарларда хезмәт күрсәтү өчен алына торган җыемнан 20 процентка кадәр ташлама ясала.

Казан Шәһәре базарларының адреслары:

1. 1 нче номер колхоз базары—Колхоз урамында; 1, 4, 5 һәм 8 нче маршрут трамвайлары бара. Телефон 23—67.
2. Суконный базары—Свердлов урамында; 4 нче маршрут трамвае бара. Телефон 29—34.
3. Ягодный базары—Ягодный бистәсе, Краснококшай урамында; 5 нче маршрут трамвае бара. Телефон 22—29.
4. Чехов базары—Чехов урамында; 3, 6 һәм 2 нче маршрут трамвайлары бара. Телефон 24—51.
5. Бассейн базары—Олькенецкий урамында; 3 һәм 6 нчы маршрут трамвайларының Кызыл Армия йорты янындагы тукталы. Телефон 38—14.

139—1 КАЗАН ШӘҺӘРЕ БАЗАРЛАР ИДАРӘСЕ.

„ТРАНСЭНЕРГОКАДР“ НЫҢ КАЗАН БҮЛЕГЕ

КОЧЕГАРЛАР хәзерләү буенча шушы ел, 1 нче февральдән (уку срогы 2 ай, укыту өчен түләү 271 сум),

ЭЛЕКТРОМОНТЕРЛАР хәзерләү буенча 10 нчы февральдән (уку срогы 3 ай, укыту өчен түләү 408 сум) һәм локомобильләр, шулай ук пар машиналары өчен

МАШИНИСТЛАР хәзерләү буенча 10 нчы февральдән (уку срогы 2 ай, укыту өчен түләү 408 сум)

КУРСЛАР АЧА

Курсларга предприятиеләрдән бирелгән командировкалар белән генә алына. Казан, Банк урамы, 15. 152—2—1

Яшеллек төзелешенең Казан тресты—Горзеленострой

предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм частный кешеләрнең ишек алларын яшелләндерү буенча барлык кирәкле эшләрне үтәү өчен

ЗАКАЗЛАР АЛА ҺӘМ ДОГОВОРЛАР ТӨЗИ

Трестның питомнигыннан декоратив материаллар, җимеш һәм җиләк үсентеләре (агачлар һәм куаклыклар) алырга мөмкин. Трестның адресы: Казан, Лобачевский урамы, 5. Телефон 44—25, Питомникның адресе: Казан, Оренбург тракты (элекке Каргопольский казармаларга каршы). Телефон: 2—81. 156—2—1

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ

Москва 4 нче труппасының — соңгы гастрольләре —

ИНТЕРМЕДИЯ

ЧИК ЙОЗАКТА

РСФСР ның атказанган артисты орденлы **М. ЗОЛЛО** үзенең антропозоологик — труппасы белән —

Атнаның икенче көнендә цирк эшләми.

Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 1 гә һәм кич 5 тән 8 гә кадәр ачык.

Галиәсгар Камал исемендәге Татар Дәүләт Академия театры

28, 29 һәм 30 нчы гыйнварда спектакльләр — булмый. —

31 нче гыйнварда, шулай ук 1 һәм 2 нче февральдә ПРЕМЬЕРА

БУЛАК АРТЫ „РЕСПУБЛИКАСЫ“

Талоннар: 105, 106 һәм 107.

Спектакльләр кич 7 сәгать 30 минутта башлана. Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 9 га кадәр ачык. ТДАТ.

3 фазалы, беренче басымы 6.000 вольт, икенче басымы 220-380 вольт һәм 100 киловатт куәтле яңа

ТРАНСФОРМАТОРНЫ

икенче басымы 127-220 вольтлы шундый ук трансформаторга

АЛМАШАБЫЗ

Казан, Холодильник. Телефон 22—76. 154—4—1

Казан Ит комбинатына ПЛАННАР БҮЛЕГЕ НАЧАЛЬНИГЫ һәм ХЕЗМӘТ БУЕНЧА ЭКОНОМИСТ кирәк. Казан, Тимер юл урамы, 3. 116—2—1

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ

Бүген, 28 нче гыйнварда **МАСКАРАД** Талон 86.

29 нчы гыйнварда **РЕВИЗОР**

Спектакльләр кич 7 сәгать 30 минутта башлана. Билетлар көндез 11 сәгать 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 8 сәгать 30 минутка кадәр кассада сатыла.

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО“ 12-30, 2-45, 7-45 һәм 10 да,	ИНЖЕНЕР КОЧИННЫҢ ЯЛГЫШУЫ
„УНИОН“ 11, 1-20, 3-40, 6, 8-20, 10-30 да.	МИНИН ҺӘМ ПОЖАРСКИЙ
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ“ 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да	ТАЙГА ЕРАКЛЫКЛАРЫНДА
„ЧАТКЫ“ 6, 8 һәм 10 да.	ИНЖЕНЕР КОЧИННЫҢ ЯЛГЫШУЫ
„ПИОНЕР“ 11, 1, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	Көндез ПОЕЗД МОСКВАГА БАРА Кич УКЫТУЧЫ Көндез 1 сәгатьтә мәктәпкә кадәр яштәге балалар өчен сеанс.
„РОТ-ФРОНТ“ 4, 6, 8, 10 да.	ДОКТОР КАЛЮЖНЫЙ
КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7, 9 да.	Степан Разин

А. КАРИЕВ

1905 нче ел революциясе татар җәмәгатьчелегендә прогрессив элементларның киң хәрәкәтен тудырды.

1906 нчы елда Казанда беренче тапкыр җәмәгать спектакле куелды. 1907 нче елда Казан һәм Оренбург яшьләреннән беренче тапкыр театр коллективы оештырылды. Бу коллективта С. Гыйззәтуллина, Кулалаев, Кудашев иптәшләр бар иде. Шул ук елны Мәкәрҗә ярминкәсендә бу коллективка Уральскидан килгән егет Миңлебай Хәйруллин кушылды һәм беренче чыгышлары белән үк ул үзендә артистлык таланты барлыгын күрсәтте.

Озакламый бу коллектив тарала, яңа коллектив төзелә, аңар „Сәяр“ исеме бирелә, коллектив башында Миңлебай Хәйруллин тора, һәм бу кеше моннан соң Абдулла Кариев исеме белән бөтен театр, сәнгать дөньясында атаклы булып китә.

А. Кариев Г. Тукайның мәдрәсә иптәше һәм дусты иде, Г. Камал һәм Ф. Әмирханның иң якын дусты иде. Ул әдәбият мәсьәләләрен тирән аңлаган кеше буларак, труппа тирәсенә иң алдынгы драматург һәм язучыларны туплады. „Сәяр“ труппасының иҗад үсешендә Г. Камал аеруча мактаулы урын тота. Г. Камал 100 гә якын оригинал һәм тәрҗемә пьесалар язды, шуларның күпчелеге „Сәяр“ труппасында уйналды һәм аларның күбесен А. Кариев үзе сәхнәгә куйды. Г. Камалның „Банкрот“, „Бәхетсез егет“, „Безнең шәһәрнең серләре“, „Беренче театр“ кебек аерым әсәрләре труппада һәр вакыт куелып килә торган төп репертуар фондын тәшкил итәләр иде.

А. Кариев, беренче тапкыр буларак, татар театры сәхнәсенә бөек классикларның: Островскийның „Гроза“, М. Горькийнең „Мещаннар“, Шиллерның „Мәкер һәм мәхәббәт“, Һейненең „Әлмансур“ дигән әсәрләрен куйды.

Бу хезмәтләрнең һәммәсен татар артистлары реакциянең котырынган елларында, жандармерия һәм патша цензурасының кысуы астында, патша тәртипләрен саклаучы татар динчеләре һәм буржуазиясенең пычрак һөҗүмнәре шартларында үтәп бардылар. Бу кешеләр, утрак урыннары

булмаган, ач-ялангач „брамат кәмитчеләр“, шәһәрдән-шәһәргә сөрелеп, хәерче тормыш кичереп, үзләренең артистлык хезмәтләрен горурлык белән башкарып килделәр, чөнки алар халык хакыйкате өстенлек алачагына, кешенең хезмәте азатлык табачагына ышанып килделәр.

Октябрь революциясе татар театрында упкын эченнән тартып алды һәм аның алдына киң иҗад үсешенең юлларын ачты, чын халыкчыл сәнгать үстерү өчен халык арасыннан яңадан яңа талантлар чыгарды.

Чехо-словаклар фетнәсе вактында А. Кариев Казанда була. Учредилкачылар А. Кариевка һәм аның иптәшләренә һичбер төрле иҗад мөмкинлеге бирмиләр. „Сәяр“ тарала. А. Кариев Уфага китә. Ул ак генералларның агентурасы—татар учредилкачыларының „эшләрен“ күреп нәфрәтләнә. Ак бандитларның төрмәләренә ташланган совет интеллигенциясенең язмышы өчен бик борчыла, аларны азат итү, качыру эшләренә ярдәмләшә һәм материаль ярдәм күрсәтә. Озакламыйча ул контрразведка күзеннән качып, Петропавлыскийга китә.

1919 нчы елның ахырында Казанга кайта. Военколлегия каршында төзелгән татар театрына хезмәткә керә. Монда эшләү аңа насыйп булмый, ул тиф белән авырый башлый һәм 1920 нче елның 28 нче гыйнварында үлә. Кызыл Армия сугышчылары һәм Казанның хезмәт ияләре аны зур хөрмәт белән күмәләр.

А. Кариев, артист буларак, һичбер вакыт онытылмаслык образлар тудырды. „Банкрот“тагы Кәрим бай, „Галия бану“ дагы Бәдри, „Хаҗи әфәнде“ дәге Хаҗи, „Шәһәр серләре“ ндәге Хафиз, „Мәкер һәм мәхәббәт“тәге Миллер һ. б.—болар онытылмас иҗад гөлләре булып торалар. Аның постановкалары тормышны дөрес чагылдыра һәм тирән ышандыручанлык белән балкып торалар иде.

Буржуа милләтчеләре А. Кариев исеменнән уттан курыккан кебек куркалар иде. Чөнки ул гүзәл киләчәк өчен батырларча көрәшкән халыкның чын вәкиле булып килде. Безнең яшьләребез А. Кариевны һәм аның дусларын, көрәштәшләрен аз беләләр. Татар театры пионерлары тормышының гүзәл сәхифәләрен бөтен халык өчен ачып бирү язучылар һәм театр җәмәгатьчелегенең мактаулы бурычы булып тора.

Фәтхи Бурнаш.

Җаваплы редактор Һ. АБДРАХМАНОВ.
Ответ. редактор Х. АБДРАХМАНОВ.

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А — 2495 ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА, ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 361.